МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.05.2018 Казан ш. № 226

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы каршындагы
Иҗтимагый совет турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне расларга.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Министр** **Ф.С.Габделганиев**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 17 маендагы 226 номерлы боерыгы белән
расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ КАРШЫНДАГЫ ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет (алга таба - Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба - Министрлык) каршындагы киңәшмә орган булып тора, ул Татарстан Республикасында гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдырганда һәм гамәлгә ашырганда дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган башка оешмаларның хокукларын, гражданнарның сыйфатлы хезмәтләр күрсәтелүгә хокукларын, аларның нәтиҗәлелеген һәм иминлеген гамәлгә ашыру, халыкка хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә контроль һәм күзәтчелекнең дәүләт системасын камилләштерү белән бәйле мәсьәләләрне карый, шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә) каралмаган башка вәкаләтләрне башкара.

1.2. Иҗтимагый советның әгъзалар исәбе һәм составы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана торган Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитеты, ведомстволары каршындагы Иҗтимагый советны төзү тәртибенә нигезләнеп, Министрлык боерыгы белән раслана.

1.3. Иҗтимагый совет үзенең эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып башкара.

1.4. Иҗтимагый совет карарлары тәкъдим итү рәвешендә була.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычларында башкара.

1.6. Иҗтимагый совет эше ихтыяри нигезгә, ачыклык һәм парнерлык принципларына һәм катгый рәвештә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына корыла.

1.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге гражданлык җәмгыяте институтлары вәкилләренең, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының, массакүләм мәгълүмат чараларының үзара кызыксынулы булуына нигезләнеп гамәлгә ашырыла.

## 2. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең максатлары һәм бурычлары

2.1. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары:

Татарстан Республикасының икътисадый үсешенә идарә итү буенча дәүләт сәясәтен булдырганда гражданнарның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган башка оешмаларның хокукларын яклау;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәсьәләләре" 2007 елның 23 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы турында нигезләмәдә (алга таба – Министрлык турында нигезләмә) каралган Министрлык компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләүгә иҗтимагый, һөнәри һәм иҗади берләшмәләрне җәлеп итү, Министрлык эшчәнлегенең һәркем өчен ачык булу принцибын тормышка ашыру;

Министрлык буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатына җәмәгатьчелек контролен көчәйтү, дәүләт хезмәтләрен күрсәткәндә ачыклык, законлылык һәм профессиональлек принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый совет бурычлары:

Министрлык турында Нигезләмәдә каралган Министрлык компетенциясенә кертелгән өлкәләрдә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Министрлык турында Нигезләмәдә каралган Министрлык компетенциясенә кертелгән мәсьәләләргә кагылышлы норматив хокукый актларның проектларына җәмәгать экспертизасын ясау, шул исәптән Татарстан Республикасы хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан эшләнә торган дәүләт программалары проектлары турында фикер алышу;

Министрлык тарафыннан карарлар кабул ителгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Министрлык эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелек хәбәрдарлыгын арттыру;

Иҗтимагый совет утырышларында "2015 - 2020 елларга Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында коррупциягә каршы сәяәстне гамәлгә ашыру" коррупциягә каршы ведомство программасы (алга таба - ведомство программасы) үтәлешенә җәмәгатьчелек экспертизасын ясау.

2.3. Иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары, аның эш нәтиҗәләреннән чыгып, шулай ук Россия Федерациясендәге икътисадый, социаль һәм сәяси вәзгыятьне исәпкә алып, үзгәртелергә һәм аңа өстәмәләр кертелергә мөмкин.

## 3. Иҗтимагый совет составы

3.1. Иҗтимагый совет составы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана торган Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитеты, ведомстволары каршындагы Иҗтимагый советны төзү тәртибенә нигезләнеп төзелә.

3.2. Иҗтимагый совет Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә Министрлык тарафыннан 13 кешедән гыйбарәт составта ихтыяри катнашуга нигезләнеп төзелә.

3.3. Иҗтимагый совет составына Россия Федерациясе гражданнары, шул исәптән иҗтимагый оешмаларның һәм коммерциягә карамаган социаль юнәлешле башка оешмаларның вәкилләре булып торган Россия Федерациясе гражданнары керә ала. Бу вакытта аларның һөнәри сыйфатлары, Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләр турында фикер алышу өчен кирәкле белемне, әлеге өлкәдә эш тәҗрибәсен кертеп, исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлар белән беррәттән Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тәкъдим иткән затлар да кертелә, аларның саны Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми исәбенең яртысыннан ким булмаска тиеш.

Иҗтимагый совет составына элек Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән затлар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми исәбенең биштән бер өлешеннән артып китмәгән санда керә ала.

3.4. Элек Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән, суд карары нигезендә юридик хокукка ия түгел дип танылган, үтмәгән яки кире алынмаган хөкеме булган затлар, шулай ук "Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында" 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмаган башка затлар Иҗтимагый совет әгъзалары була алмыйлар.

3.5. Иҗтимагый советның персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана.

3.6. Министрлык, Иҗтимагый совет составы расланган көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча, Иҗтимагый советның беренче утырышын үткәрүне оештыра, анда әгъзалар арасыннан Иҗтимагый советның рәисе, рәис урынасары сайлап куела. Карар ачык тавыш бирү юлы белән Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санына карата күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.7. Иҗтимагый совет рәисен һәм рәис урынбасарын вазыйфасыннан азат итү турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы икътисад министры (алга таба - министр) мөрәҗәгате буенча, шулай ук Иҗтимагый совет рәисенең яки рәис

урынбасарының шәхси гаризасы яисә Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан кимендә биштән бер өлешеннән гыйбарәт Иҗтимагый совет әгъзалары төркеменең тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет тарафыннан карала. Карар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санына карата күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.8. Иҗтимагый совет рәисе Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның җаваплы секретарен билгели.

3.9. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре срогы яңа төзелгән Иҗтимагый совет составының беренче утырышы үткәрелгән көннән алып өч ел тәшкил итә.

3.10. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Министрлык боерыгы нигезендә түбәндәге очракларда туктатылып тора:

Россия Федерациясе җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә ул җинаять кылуда гаепләнсә;

административ кулга алу рәвешендә аңа административ җәза билгеләнсә;

аны дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутатына кандидат, җирле үзидарә органында сайланулы вазыйфага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы заты яки вәкаләтле вәкиле буларак теркәсәләр, шулай ук ул Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына кергән очракта.

3.11. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракта туктатыла:

аны вәкаләтләр срогы бетсә;

Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза язса;

сәламәтлеге торышы буенча Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмаса;

аңа кагылышлы чыгарылган гаепләүле суд хөкеме законлы көченә керсә;

законлы көченә кергән суд карары нигезендә юридик яктан хокуксыз дип яки билгесез сәбәпләр аркасында булмавы танылса;

аның тарафыннан әхлак нормалары тупас бозылса – утырышта катнашучы Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

Иҗтимагый совет утырышларының эшендә җитди сәбәпләрсез системалы рәвештә (өч тапкырдан күбрәк) катнашмаса;

Иҗтимагый совет рәисенең яки рәис урынбасарының йөкләмәләрен җитди сәбәпләрсез системалы рәвештә (ике тапкырдан күбрәк) үтәмәсә;

Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яки муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куелса;

ул чит дәүләт гражданлыгын (подданные) алса;

Россия Федерациясе гражданлыгы бетсә;

3.12. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктату, Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасына йә Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары тәкъдименә нигезләнеп, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.11 пунктында каралган

шартларның булуы ачыкланган очракта Министрлык боерыгы нигезендә башкарыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 3.11 пунктындагы дүртенче, бишенче, унынчы – уникенче абзацларында каралган шартларның барлыкка килүе турында Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

Министрлык инициативасы белән үткәрелә торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, "түгәрәк өстәл"ләрдә һ.б.) катнашырга, моңа дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләрне, персональ мәгълүматлар турындагы белешмәләрне үз эченә ала торган мәгълүматлар һәм файдаланылуы чикләнгән мәгълүматлар кулланылуга бәйле рәвештә федераль законнар нигезендә керү чикләнгән чаралар керми;

инициатива белдереп, Иҗтимагый советка аналитик язмалар, докладлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләргә һәм юлларга;

Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

көн тәртибе мәсьәләләрен карауда катнашу өчен Иҗтимагый совет утырышларына чакырыла торган затларның кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгарга.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә бурычлы:

Иҗтимагый совет рәисе биргән йөкләмәләрне үтәргә;

әлеге Нигезләмәдә каралган Иҗтимагый советның эшләү тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга;

экспертиза төркемнәре, эшче төркемнәр, комиссияләр, Иҗтимагый совет тарафыннан аңа йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен төзелә торган башка эшче органнар эшендә катнашырга;

## 5. Иҗтимагый советның эшләү тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет утырышында раслана торган планнарга һәм программаларга нигезләнеп оештыра.

5.2. Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзаларының, Иҗтимагый совет рәисенең һәм Министрлыкның тәкъдимнәренә нигезләнеп башкарыла.

5.3. Иҗтимагый совет утырышы иң сирәге кварталга бер тапкыр үткәрелә.

Иҗтимагый совет утырышлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнә торган, әлеге башкарма хакимият органнары каршындагы

иҗтимагый советлар утырышында алдан фикер алышмыйча кабул ителә алмаган норматив хокукый актларның һәм башка документларның составын раслау турында" 2013 елның 29 мартындагы 214 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнә торган, әлеге башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышында алдан фикер алышмыйча кабул ителә алмаган норматив хокукый актларның һәм башка документларның исемлегендә каралган һәм Министрлык тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актлар проектларына һәм теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына билгеләнгән тәртиптә җибәрелә торган норматив хокукый актларга Иҗтимагый совет бәяләмәсен бирү максатларында Министрлык инициативасы буенча үткәрелә.

5.4. Иҗтимагый совет утырышлары, әгәр аларда Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашса, хокуклы булып санала. Иҗтимагый совет әгъзасы утырышта шәхсән катнаша алмаса, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз тавышын һәм үз фикерен Иҗтимагый советның башка әгъзасына язма рәвештә, факсимиль яки электрон почта аша тапшырырга хокуклы, тик бу хакта алдан ук Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына, яисә Иҗтимагый советның җаваплы секретаренә хәбәр итеп куярга тиеш. Утырышта катнашучы Иҗтимагый совет әгъзалары исәбенә үз тавышларын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары өстәлә.

Әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларының (норматив хокукый актларның) Иҗтимагый совет тарафыннан каралуы аларны Иҗтимагый советка Министрлык җибәргән көннән алып ун календарь көн эчендә башкарыла. Шул ук вакытта алар буенча Иҗтимагый совет бәяләмәләрен бирү максатларында тавыш бирүне үткәрү Иҗтимагый советның барлык әгъзаларын сораштыру рәвешендә читтән торып тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырыла, сораштыру нәтиҗәләре соңыннан беркетмәгә кертелә, аны Иҗтимагый совет рәисе, ә ул булмаган очракта – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары имзалый. Мондый тавыш бирү, почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон яки тапшырыла һәм алына торган хәбәрләрнең аутент булуын һәм аларның документлар белән раслануын тәэмин итә торган башка элемтә чараларын кулланып, документлар алмашу юлы белән үткәрелергә мөмкин. Читтән торып тавыш бирү үткәрелгән очракта, Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына, барлык әгъзаларына тәкъдим ителә торган көн тәртибе, Иҗтимагый советның бәяләмәсен бирү сорала торган норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) аны үткәрү көненә кадәрге җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрелә. Иҗтимагый совет әгъзалары, кирәк булган очракта, карала торган норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча өстәмә материалларны һәм мәгълүматны Министрлыктан соратып ала.

Ведомство программасының үтәлешен Иҗтимагый совет тарафыннан карау Министрлык каршындагы Иҗтимагый советның турыдан-туры катнаша торган утырышларында иң азы кварталга бер тапкыр башкарыла.

Иҗтимагый совет карарлары тавышларның гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда Иҗтимагый совет утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Иҗтимагый совет карары белән, кирәк булган очракта, эшче төркемнәр төзелә.

Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.5. Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе, ә ул булмаган очракта – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары үткәрә.

5.6. Иҗтимагый совет тарафыннан аңа йөкләнгән максатларга, бурычларга, вәкаләтләргә ярашлы кабул ителә торган карарлар тәкъдим итү рәвешендә була һәм кызыксынулы затларга Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсеннән өземтә рәвешендә яисә Иҗтимагый совет билгеләгән башка ысул белән җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый советның эшчәнлеге турындагы мәгълүмат Министрлыкның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында өстәмә кушымтага урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

Иҗтимагый совет утырышын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзаларының тәкъдимнәренә нигезләнеп, Иҗтимагый советның эш планын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Иҗтимагый совет раславына тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет утырышын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый советның тәкъдимнәрен, беркетмәләрне һәм Иҗтимагый советның башка документларын имзалый;

Иҗтимагый совет утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый совет эшчәнлеге, аңа йөкләнгән максатлар һәм бурычлар кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән соратуларны, рекомендацияләрне, тәкъдимнәрне, җавапларны, аңлатмаларныһәм мөрәҗәгатьләрне имзалый;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә урынында булмаган очракта, аның функцияләрен башкара;

Иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышлары өчен көн тәртибен төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисе раславына тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет рәисе йөкләмәсе буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.10. Иҗтимагый совет секретаре:

утырышларга материаллар һәм беркетмәләрнең проектларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый совет утырышын үткәрү урыны һәм вакыты, көн тәртибе турында мәгълүмат бирә, аларны кирәкле мәгълүмат-белешмә материаллар белән тәэмин итә;

Иҗтимагый совет белән Министрлыкның оештыру эшләрендәге үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

Иҗтимагый совет утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшереп тора;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары мәсьәләләрне Иҗтимагый совет утырышларында тыңлауга һәм фикер алышуга әзерләү өчен эшче, эксперт төркемнәренә һәм башка эшче органнарга берләшергә, материалларны әзерләүгә Иҗтимагый совет составына кермәгән белгечләрне, Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килештереп, җәлеп итәргә мөмкин.

5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый совет тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләр һәм бәяләмәләр бирү өчен дәүләт хакимияте органнары, коммерциягә карамаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм башка белгечләр чакырылырга мөмкин. Иҗтимагый совет әгъзалары булып тормаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет чакыруы буенча Иҗтимагый совет утырышларында катнаша ала. Иҗтимагый совет үз эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларының катнашуын тәэмин итә.

5.13. Иҗтимагый совет каравына кертелә торган материаллар аларны карау күз алдында тотылган Иҗтимагый совет утырышының билгеләнгән көненә кадәр кимендә ун календарь көн кала Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына тапшырылырга тиеш. Материалларны соңрак срокларда тапшыру Иҗтимагый совет рәисе яки Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килештерелә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне Министрлык гамәлгә ашыра.